**Исполнительный комитет Новоспасского сельского поселения Заинского муниципального района Республика Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең башкарма комитеты**

Ул. Молодежная, д. 13, с. Новоспасск, Заинский район, 423535

Молодежная урамы, 13 нче йорт, Яңа Спас авылы, Зәй районы, 423535

Телефон, факс 64-5-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru, сайт: www.zainsk.tatarstan.ru/rus/novospasskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«09» апреля 2020 г.**

**КАРАР**
**№6**

«Яңа Спас авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Спас җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү тәртибен һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **А.С.Быля**

Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитетының
2020 елның 9 апрелының 6 номерлы карары
белән расланды

**Яңа Спас авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Яңа Спас авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Яңа Спас авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү кагыйдәләрен (алга таба - тәртип, муниципаль берәмлек) билгели.

2. Әлеге тәртиптә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба - гомуми таләпләр) белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр белән билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла.

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар, муниципаль программаларның структур элементлары һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында муниципаль берәмлек башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы11нче номерлы районара салым идарәсенә( алга таба ФСХ ТР №11 РАСИ) 1 сентябрьгә кадәр муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хисап елына, хисап елына кадәрге ел өчен түбәндәге белешмәләрне җибәрүне тәкъдим итәргә:

ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;

Яңа Спас авыл җирлеге бюджетының керми калган керемнәре суммалары турында

Яңа Спас авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча.

Муниципаль берәмлек салым чыгымнарының расланган исемлеге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында ФСХ ТР №11 РАСИ муниципаль берәмлек башкарма комитетына хисап финанс елы өчен һәм хисап чорына кадәрге ел өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүмат бирә.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру максатларында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты ел саен, 1 августка кадәр, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, муниципаль берәмлекнең тиешле салым чыгымнарын билгеле торган, шул исәптән хисап елында һәм алдагы елда гамәлдә булган норматив хокукый актларын һәм әлеге тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында белешмәләр җибәрә.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергәннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә тиешле үзгәрешләрне кертә.

## III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе

10. Салым чыгымнарын бәяләү муниципаль берәмлек башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләүне;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгын бәяләүне;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне.

12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып тора:

муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарының муниципаль программаларның максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

салым түләүчеләрнең ташламалардан файдаланучылар саны һәм бишьеллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана торган салым ташламаларына ихтыяжлы булу.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәсә дә, муниципаль берәмлек башкарма комитетына түләүчеләр өчен ташламаларны саклау (анықлау, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр тапшыру кирәк.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының нәтиҗәлелек критерие буларак муниципаль программа максатларына яисә муниципаль программаларга керми торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең ким дигәндә бер күрсәткече (Индикаторы) яисә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары йогынты ясый торган башка күрсәткеч (индикатор) буларак билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елына, хисап елына кадәрге елга, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеләнә.

Салым түләүчеләр өчен каралган ташламалар муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) әһәмиятен үзгәртүгә кертелгән өлеш, ташламаларны исәпкә алган күрсәткеч зурлыгы һәм ташламаларны исәпкә алмаган күрсәткеч зурлыгы аермасы буларак, бәяләнергә тиеш.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә һәм ташламалар бирү нәтиҗәлелегенә чагыштырмача анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану очрагында муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен чагыштыруны, муниципаль берәмлек муниципаль программасы максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторның) һәм муниципаль берәмлек муниципаль программаларына карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларының муниципаль программаларга туры килмәгән күрсәткечләренең (индикаторның) артуын муниципаль берәмлек программаларының салым чыгымнарының 1 сумына һәм, альтернатив механизмнар кулланылган очракта, шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен, муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумына исәпләп чыгаруны үз эченә ала.

Муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган

социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында исәпкә алынырга мөмкин:

а) субсидияләр яисә муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән ташламаларга хокуклы түләүчеләргә турыдан-туры финанс ярдәменең башка рәвешләре;

б) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләрне бирү;

в) ташламаларга хокуклы түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә норматив жайга салуны һәм (яки) контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр башкарыла һәм үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге буенча мәгълүматны;

- салым чыгымнарының максатчан характеристикаларына ирешү (ирешмәү), муниципаль программа максатларына һәм (яисә) социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә салым чыгымының өлеш кертүе турында нәтиҗәләрне үз эченә алган язмача аңлатма;

- нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнар булу (булмау) турында тәкъдимнәр;

- салым чыгымнарын саклау, аныклау (юк итү), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтижәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә кушымта

Яңа Спас авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге

| Күрсәткеч исеме | | Мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|
| I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан характеристикалары | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнан азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, салымнан азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3. | Салым ташламалары, салымнан азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламалары, азат ителү һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары үз көченә керү датасы | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары тарафыннан салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча башка преференцияләргә хокук гамәлдә булуның башлану датасы | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламалары, азат ителү һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары, азат ителү һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуы туктатылу датасы | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 8. | Салым ташламалары, азат ителү һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 9. | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 10. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым түләүчеләр өчен салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр бирүнең максатлары | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |

| | | |
|---|---|---|
| 11. | Салым ташламалары, азат итү һәм муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән башка преференцияләр каралган салым исемнәре | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 12. | Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләрнең башка түләүчеләр белән чагыштырганда өстенлекләре үзенчәлекләрен билгели торган төре | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 13. | Салым ташламалары, азат итү һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 14. | Салымнар буенча салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләр бирү белән бәйле рәвештә муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткечләре (индикаторлары) | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| | **II. Салым чыгымнарының фискаль характеристикалары** | |
| 15. | Хисап елы өчен һәм хисап елына кадәр булган ел өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләме (мең сумнарда) | ФСХ ТР №11 РАСИ (килешү буенча) |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сумнарда) | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 17. | Салым ташламасыннан, азат итүдән һәм муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән башка преференциядән (берәмлекләрдән) файдаланучы салым түләүчеләр саны | ФСХ ТР №11 РАСИ (килешү буенча) |
| 18. | Салым чыгымнары тәэсирен бәяләү нәтиҗәсе | Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты |